Yäkşämbe, 25 April 2004

tügərək əstəl

**Qazanım, Qazanım... AQŞ professorı William C. Brumfield belän äñgämä**

***Qazanım, Qazanım....dip isemlängän tapşırular şälkemen däwam itäbez, xörmätle tıñlawçılar. Bu programmalarda sezneñ iğtibarğa Qazannıñ meñ yıllığın bilgeläwgä äzerlänüe, şulay uq şähär tormışı, anıñ mädäniäte, Qazan turında qızıqlı äñgämälär täqdim itäbez. Başqalanıñ zamança şähärgä äylänä barğanda anıñ tarixi mirasın saqlap qalu yulların tabu – iñ zur problemalarnıñ berse. Amerikan arxitektorı, tarix belgeçe William Brumfield Qazannı inde 20 yılğa yaqın waqıt belä. Anıñ belän Qazan turında söyläşäbez.***

**William Brumfield**'nı Rusiädä kübräk fotorässam häm arxitektor bularaq belälär. Anıñ berençe tapqır 1993nçe yılda çıqqan **Rusiä arxitekturası tarixı** dip isemlängän kitap – bik küp illärdä arxitektorlar öçen däreslek kebek xezmät itä. William äfände – Quşma Ştatlarnıñ New Orleans şähärendäge Tulane universitetında – Rusiä tikşerenüläre professorı. **William Brumfield** universitta uqıta, bik küpä säyäxätkä çığıp tarixi urınnarnı räsemgä töşerä, şulay üzeneñ xezmäte belän Amerikan cämäğätçelegen tanıştıra. Äytik 24 april könne Waşingtonda Smithsonian İnstitutında "Rusiä häm Tatar bäyläneşe" isemle seminar uzdı. Anda seber häm Mongoliä çigennän alıp Çiläbe-Magnitogorski häm Mäskäwgä qadär tatar arxitektura ürnäkläre turında çığışlar yañğradı häm älbättä inde bik küp räsemnär kürsätelde. Cıyınnıñ ber öleşe şulay uq ayırım Qazanğa bağışlanğan ide. Monnan ber ay elek dönyanıñ iñ mäşhür muzeylarınıñ bersendä, New Yorktağı Metropol muzeyında Qazan turında ike leksiä tıñlarğa häm Brumfieldnıñ räsemnären qararğa yözlägän keşe cıyılğan bulğan. William äfändeneñ seminarları cämäğätçelekkä açıq, anda ğalimnär häm belgeçlär belän bergä uqıtuçılar häm studentlar, bolay ğına qızıqsınuçılar da qatnaşa ala. William Brumfield iseme Quşma Ştatlarda – ğalim, Yevraziä arxitektirası belgeçe häm fotorässam bularaq bilgele. Bezne bügen tanılğan arxitektornıñ Qazan turındağı fikerläre qızıqsındıra.

AQ: Sez Qazanğa berençe tapqır qayçan bardığız?

WB: *1985nçe yılnıñ cäy urtası, iül ayı. Min Rusiägä kilep İdel buylap köymädä säyäxätkä çıqqan amerikan turistlarınıñ berse idem. Ul çaqta bez Mäskäwdän Qazanğa oçqıç belän kildek häm yulnı Volgogradqa taba İdel buylap däwam ittek.*

AQ: Dimäk iñ berençe Qazan räsemnäre dä näq şul yılnı töşerelgänme?

WB: *Eye ul çaqta üzem öçen bik möhim räsemnär töşerdem. Alar xäzer dä miña bik qaderle, çönki şähär bu waqıt eçendä nıq üzgärde.*

AQ: Sezneñ räsem kitaplarığızda Rusiäneñ bik yıraq poçmaqlarında, çit il turistı ğına tügel, Rusiä keşese ğömer buyına da barıp citmägän awıl-şähärlärneñ fotoları bar. Niçek taptığız andıy urınnarnı?

WB: *Seberdäge eşemä kilgändä, miña kongress (amerikan kongressı) kitapxanäse küp bulıştı. Kongress uqıtuçılar, studentlar, cämäğätçelek öçen internetta ber säxifä buldırğan. "Çik buyında oçraşu" dip atala ul. Anda Amerikanıñ könbatışqa taba, Rusiäneñ könçığışqa taba kiñäyüe turında qızıqlı mäğlümatlär urın alğan. Min Quşma Ştatlarda kiñ tanılğan foto rässam häm tarixçı, häm minnän – Rusiäneñ könçığışqa taba kiñäyüen tarix öçen foto räsemnär yardämendä qaldırıyq, dip soradılar, minem fotolar aşa. Ul çaqta min inde 20 yılğa yaqın Rusiäneñ üzäk öleşendäge tarixi arxitektura belän yaxşı tanış idem. Şulay itep 1999nçı yıldan başlap min kübräk Rusiäneñ könçığışında eşli başladım. Xäzer kongress kitapxanäsendä min urnaştırğan tarixi mäğlümatlär dä bar. Seber şähärläre arxitekurası Rusiäneñ başqa töbäklärenä oxşağan da, oxşamağan da. Biredä yäşäwçe başqa bik küp törle millät wäkilläre dä arxitekturağa üz öleşlären kertkän. Näq Qazanda kebek – biredä dä Yevropa belän Aziä, törle mädäniätlär häm dinnär qatnaşqan arxitektura ürnäklären küräseñ. Bu yaqtan minem öçen Qazan da bik qızıqlı.. Ämma şunı äytäsem kilä – min ber qayçan da ber qaya da äzerleksez barmıym. Min şulay uq tarixçı da. Rusiä tarixı turında kitaplarım bar. Häm bälki kemder öçen minem räsemnärem – yalğış qına barıp foto töşergän kebek kürensä – bu döres tügel. Min barır cirlärne üzem saylıym.*

AQ: Qazannıñ Yevropa häm Aziä yöze turında söylädegez. Şul süzläregezgä kire qaytıp ber soraw biräsem kilä. Sez inde 20 yılğa yaqın waqıt Qazandağı üzgäreşlärne küzätep barasız. Tatarstan häm Qazan räsmilärennän yış qına Qazannan Yevropa standartındağı şähär yasıybız digän süzlär işetep bula. Sezneñçä alar döres yuldamı?

WB: *Bu ber Qazannıñ probleması ğına tügel. Dönyadağı bik küp şähär citäkçeläre dä – iske tarixi binalar belän nişlärgä belmi . Bu problema ğadättä állä qayçannan birle kilgän bula, çönki binalarnıñ cimerelüe säbäbe – alarnıñ waqıtında qaralmawı. Alarnı cimerergäme? Urınına yañalarnı tözergäme? Äytüemçä, bu Qazan probleması ğına tügel. Qazanda – tarixi qorılmalarnı saqlawğa qarata yaxşı mönäsäbät sizelä. Äytik, timer yul vokzalı binası bik yaxşı saqlanğan häm tözekländerelgän. Qızğanıçqa qarşı bik küp başqa şähärlärdä, mäs'älän Samarda bu binalar cimerelde. Şähärgä kilüçelärneñ başqala belän tanışuı – vokzaldan başlana häm kereşneñ matur buluı bik möhim. Annan soñ – Bauman uramı üzgärtelde. Anda da xakimiätlär borıñğı binalarnı saqlap qalırğa tırışqan. Boları barısı da uñay tärräqiät, süz dä yuq. Ämma şähärdä tiskäre yaqlar da bar. Zur Qızıl (Bolshaya Krasnaya), Marks uramnarında, Kremlgä yaqın keçkenä uramnarda tarixi binalar bik tiz waqıt eçendä cimerelde. Zur Qızıl uramında çirkäwne genä qaldırğannar.*

*Ämma şul borıñğı möhitne, tarixi yıllarnı iñ yaxşı çağıldırğan – yortlar, binalar – barısı da cimerelgän. Alarnıñ niçäse genä elekke stildä tözeler – monsın äytü bik awır. Menä bolar mine bik borçıy. Şulay uq ağaç yortlar arxitekutarsı......*

AQ: Eye, min süzne bülep soramaqçı bulam äle. Qaban küle artındağı tatar bistäsendä hiçşiksez bulğansızdır? Qazannıñ ul öleşe turında ni uylıysız?

WB: *Min Qazanğa berençe kilgändä, 1985nçe yılda, inde irtägä kitäbez digän könne genä şul bistägä barıp cittem. Bik arğan idem, qaytasım bar ide, qarañğı töşä ide, şuña berniçä matur ağaç yortnı ğına räsemgä töşerdem dä kittem. Soñınnan tağın kübräk räsemnär töşermägänemä bik qatı ükendem. Çönki uzğan yılnıñ may ayında minem Qazanğa Rusiä arxitektura akademiäseneñ äğzase bularaq, akademiä utırışına barğaç kürgännärem – mine şaqqatırdı. Min 1985nçe yılda töşergän uramda inde ağaç yortlar tügel, ä küp qatlı panel yortlar basıp tora inde, yanında – xokey stadionı tözelgän. Bu toraq yortlar naçar tügel, alarnıñ xatta matur yaqların da tabıp bula, ämma alar biredäge tatar mädäniäten, tatar arxitekurasın yuq itkän! Bu Sverdlaw uramı tiräsendä ide. Şulay uq Volkov uramında bik matur ike qatlı ağaç yort yuqqa çıqqan. häm başqalar häm başqalar. Tatarmı, urısmı, biredä ber ayırma da yuq, monda ğömüm mädäniät zur yuğaltu kiçerä. Tarixi miras yuqqa çığa. Säbäbe – bu borıñğı binalarnı tözekländerügä investitsiälär cälep itergä tırışmaw, anda yäşäwçelärneñ häm xakimiätlärneñ bitaraflığı – belmim närsä. Läkin Qazanda tarixi binalar yuqqa çığa bara. Citäkçelek tä tırışa närsäder eşlärgä, ansı da kürenä. Ämma bälki alarğa kübräk belgeçlär, arxitektorlar belän kiñäşläşergäder? Bu mäs'älä bik awır.*

Amerikan arxitektorı William Brumfield, inde äytkänemçä, Luiziana ştatınıñ New Orleans şähärendä yäşi. Äñgämä barışında ul ber misal kiterde. Belüegezçä Amerikada borıñğı arxitektura tabuı bik awır, şuña da biredä bulğan tarixi binalarnı saqlawğa küp iğtibar itelä. Äytik, New Orleans şähäreneñ fransuz uramı – näq iske Yevropa stilendä tözätelgän. Biredä rässamnar, cırçılar, ber süz belän äytsäk – icat keşeläre yäşi. Häm üzlärenä icadi möhit tudıru turında alar üzläre dä uylana. Qazan öçen bu misal qaysı yağı belän faydalı bula ala? Başqalada yäşäwçe xalıqnı pıçraq, cimerek uramnar häm binalarğa bitaraf bulğanı öçen ğayepläp bulamı?

AQ: Küptän tügel Qazannıñ 20 yılğa üseş häm tözekländerü planı iğlan itelde. Bu uñaydan jurnalistlarnı da cıydılar. Ul oçraşuğı Azatlıq xäbärçese dä bardı, ämma konkret mäğlümat, Qazannıñ üseş planı turında ber ni dä belä almadı. Läkin Qazan xalqınıñ üz şähärendä nilär bulıp yatqanın belergä xoquqı bar, tügelme? Moña sezneñ qaraşnı da beläse ide.

WB: *Älbättä, bu inde demokratik yäşäw turında... Amerikada mondıy plannar cämäğätçelek belän kiñäşläşep qabul itelä. Älbättä, säyer qararlar da bula, bezneñ sistema da kamil tügel. Ämma demokratiä bulğan här ildä xakimiätlär keşelärneñ yäşäw şartlarına qağılğan plannarnı häm qararlarnı şul uq keşelär belän kiñäşläşep qabul itergä tieş. Monıñ başqa yulı bula da almıy. Qararlar östän künderelsä bu turıdan turı xalıqnıñ xakimiätlärgä bulğan ışanıçın beterä.*

AQ: Häm soñğı sorawlarımnıñ berse, sez Rusiäne yaxşı beläsez, anıñ başqa töbäkläre belän çağıştırğanda, Qazanda yäşäw standartları nindiräk.

WB: *Qazan bik yaxşı tä'sir qaldıra. Min xäzer eşsezlek yäki tormışnıñ başqa sotsial problemaları turında statistik mäğlümatne belmim, ämma min aralaşqan keşelär häm kürgän cirlär yaxşı tä'sir qaldırdı. Qazanda bik küp uqu yortı bar, bay milli kitapxanä, mädäniät yortları – bolarnı barısın da idarä itep totu öçen Qazannıñ hiçşiksez yaxşı iqtisadi nigeze bulırğa tieş, dip uylıym. Qazannıñ geografik urnı da bik yaxşı. Keşelärneñ yäşäw däräcäse dä yaxşı kebek kürenä. Ämma yañadan üz temama qaytıp şunı äytäsem kilä – yaxşı yäşäw – tarixi mirasnı saqlawda da çağılsın ide digän teläk bar.*

A: Rusiädä iñ yaratqan şähäregez barmı?

B: *Äytüe bik awır, çönki minem öçen här şähär – borıñğı häm bik qaderle arxitektura misalı bulıp tora. Här şähärneñ üz yöze bar. İrkutski şähäre bik qızıq, Qazan, Tübän Novgorod – bu şähärlärdä minem berniçä tapqır bulğanım bar. Min Rusiädä yözlärçä urında buldım häm ber tapqır da – nigä monda kilep waqıt äräm ittem ikän diğänem bulmadı. Qazan – alğa taba da üzençälekle törle mädäniät, dinnär qatnaş yözen saqlap qalır digän ömettä qalam, häm älbättä Qazanğa tağın barırmın, dip uylıym.*

Azatlıq dulqınnarında sorawlarğa AQŞnıñ Tulane Universitetı professorı, tarix häm arxitektura belgeçe William C. Brumfield cawap birde.

Alsu Qormaş, Praga

arxiv

RFE/RL, INC. © 2004. Bar xoquqlar saqlanğan.